РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

30.04.2025 | № 331-п

«Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 23 мартындагы 301-п номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләү буенча Бердәм тариф сеткасы таралмаган хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру һәм «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 апрелендәге 226 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 23 мартындагы 301-п номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** карарның 1 пунктындагы дүртенче абзацында «13990» саннарын «15389»саннарына алмаштырырга.

**1.2.** 3 пунктның 3 пунктчасында «37 процент» сүзләрен «52 процент» сүзләренә алмаштырырга;

**1.3.** 7 пунктның 4 пунктчасында «37 процент» сүзләрен «52 процент» сүзләренә алмаштырырга.

**2.** Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә дип билгеләргә.

**3.** 5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

Җитәкче | М. Р. Ишниязов